

2025 елнын 10 февралендә, Мордовия башлыгы Артём Здунов инициативасы белән «Герои среди СВОих» программасын эшләтеп жибәрү кысаларында, республиканын матбугат үзәгендә брифинг узды. Анда спикерлар теркәлү башлану турында игълан иттеләр һәм беренче катнашучыларда туган мәсьәләләр турында фикер алыштылар.
Чаранын спикерлары Мордовия Республикасы башлыгы администрациясе һәм Мордовия Республикасы Хокүмәте житәкчесе урынбасары Елена Семелева, Мордовия Республикасы Дәүләт Жыелышы рәисе урынбасары, программанын Эксперт советы рәисе Наталья Долматова, шулай ук СВО ветераны Сергей Пронькин иделәр.
Брифингта Мордовия Главасы Артём Здунов морәжәгате экранда яктыртылып торды. Анда болай диелгән: «Кадерле дуслар, корәштәшләр! Без республикабызда «Герои среди СВОих» программасын эшләтеп жибәрәбез, анын нигезе «Время героев» президент программасы булды. Якын арада ветераннарыбыздан һәм гамәлдәге махсус операция сугышчыларыннан гаризалар жыя башлыйбыз. Сайлап алынганнар янадан әзерлек узарга, идарә итү күнекмәләрен кочәйтергә һәм киләчәктә Мордовия үсешенә үз олешләрен кертергә момкинлек алачаклар. Геройларыбызга һонәри юлларында гына түгел, республика хакимияте органнарына, предприятиеләренә эшкә урнашуда да ярдәм итәчәкбез.
Кадерле Мордовия сугышчылары, илнен чын патриотлары - «Герои среди СВОих» программасы сезнен турыда һәм сезнен очен! Момкинлекне кулдан очкындырмагыз - сез туган якка кирәк!»
Программанын максаты: Мордовия Республикасы дәүләт, муниципаль хакимият органнарында, дәүләт, ижтимагый оешмаларда һәм икътисаднын башка олкәләрендә эшләү очен махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм ветераннар арасыннан квалификацияле, компетентлы кадрлар әзерләү.
««Герои среди СВОих» проекты конкурсында теләсә кайсы сугышчы, гамәлдәге һәм махсус хәрби операция ветераны да катнаша ала, - дип ачык-лык кертте Елена Семелева. - Конкурста катнашуга гаризаны карау берничә этапны үздә тота. СВО зонасында булганнар очен «жинелләштерелгән» анкета варианты каралган. Алар очен шулай ук берничә этапны узунын дистанцион форматы булачак. Заявка бирү очен проект сайтына күчәргә һәм «заявка калдырырга» бүлеген сайларга кирәк. Аннары шәхси профиль булдырырга, анкета тутырырга, һонәр олкәсен күрсәтергә, тест узарга һәм кыскача эссе язарга. Һәр этапны унышлы узган очракта шәхси кабинетта яна бүлекләр ачылачак. Проект оч олештән тора: заявка бирү, конкурс нигезендә сайлап алу, укыту һәм остазлар белән стажировка узу. Махсус хәрби операция ветераны Сергей Пронькин катнашуга гариза калдырган инде. Ул анкета тутырунын кыенлыклар тудырмавын раслады; ин моһиме - интернетка тоташу һәм бераз вакыт анда булу ди».
«Герои среди СВОих» программасы республика предприятиеләрендә, шулай ук дәүләт хакимияте органнарында һонәри әзерлек һәм эшкә урнашу момкинлеген тәкъдим итә.
Наталья Долматова теркәлү башланганнан бирле беренче сәгатьләрдә 49 анкета килүен остәде.
«Бу программанын тыныч тормышка кайткан һәм тиздән әйләнеп кайтачак егетләр очен

кирәкле булуын күрсәтә. Социаль адаптация, һөнәри үз-үзенне камилләштерү һәм тормышның яна этабында үзенне эзләү бик мөһим - шуның өчен шундый әһәмиятле һәм кирәкле төбәк программасы эшләтеп җибәрелде дә инде», - дип билгеләп үтте Мордовия Республикасы Дәүләт Җыелышы рәисе урынбасары.
Программада катнашу өчен теркәлү узган СВО ветераны Сергей Пронькин брифингта болай дип сөйләде: «Программа кешеләргә киләчәккә юл ача, үз тәҗрибәнне Мордовия файдасына кулланырга мөмкинлек бирә. Теркәлү вакытында кыенлыклар булмады. Теркәлү формасы - гади анкета. Укуны котәм: үз йортына - Мордовиягә файда китерү һәрвакыт күнелле.»
Исегезгә төшерәбез, программага теркәлү 10 февральдән башланды, ә беренче уку сессиясе 1 июльдә башланачак. «Герои среди СВОих» программасы ил мәнфәгатьләрен яклаучыларга ярдәм итәргә генә түгел, ә аларга тыныч тормышка җайлашырга да ярдәм итәргә тиеш. Ул Мордовиянен киләчәген формалаштыруда мөһим адым булачак, безнен геройларга төбәк тормышында актив катнашу мөмкинлеге бирәчәк.
«Герои среди СВОих» проекты турында актуаль мәгълүмат мәйданчыклары да бар: Телеграмм: https://t.me/geroisvomordovii. Сайт: https://geroi.e-mordovia.ru/

**Наилә НАСЫРОВА**